ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово, 422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МАКЫЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 110 нче йорт, Макыл авылы, 422582

Тел.: (84379) 34-4-74, факс: (84379) 34-4-95.

18.11.2022 № 01

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?- Сеитово авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 18 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә халык җыенында катнашучы 73 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 41 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында катнашучы 41 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен - 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?- Сеитово авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге башлыгының урынбасарына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: П.Е.Карпухин